20__ елның “__” ________

боерыкка 1 нче кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫНДА ДӘҮЛӘТ ГРАЖДАН ХЕЗМӘТЕНЕҢ ВАКАНТЛЫ ВАЗЫЙФАЛАРЫН БИЛӘҮГӘ КОНКУРС ҮТКӘРҮ ТУРЫНДА

# НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү буенча конкурс комиссиясе (алга таба – конкурс комиссиясе) эше тәртибен, составын һәм эшләү срокларын билгели.

1.2. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс (алга таба – конкурс) Россия Федерациясе гражданнарының дәүләт хезмәтен биләүгә тигез хокуклылыгын, шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – граждан хезмәткәрләре) эш урынында конкурс нигезендә үсү хокукын тәэмин итә.

1.3. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында (алга таба – Министрлык) "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы һәм "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында" Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы нигезендә үткәрелә.

Конкурс граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучының һөнәри әзерлек дәрәҗәсен, аларның бу вазыйфага куелган квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

1.4. Министрлыкта конкурс, "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" Федераль закон һәм "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" Татарстан Республикасы Законы нигезендә конкурс аша биләнергә мөмкин вакант вазыйфа булган очракта, Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры (алга таба – министр) карары белән игълан ителә.

1.5. Конкурс үткәрү турында карар Министр тарафыннан структур бүлекчә җитәкчесе әзерләгән дәлилле язмача гариза нигезендә кабул ителә.

Гаризада, конкурс игълан итү турында тәкъдимнән тыш, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасының (алга таба – граждан хезмәте вазыйфасы) исеме һәм бу вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучыга карата вазыйфаи бурычларның

спецификасы исәпкә алынган таләпләр күрсәтелергә тиеш (Нигезләмәгә 1 нче кушымта).

1.6. Министрлыкта түбәндәге очракларда конкурс үткәрелми:

1.6.1. Министрлыкта граждан хезмәтенең "җитәкчеләр" һәм "ярдәмчеләр (киңәшчеләр)" категорияләре вазыйфаларына билгеләнгән вәкаләтләр чорына билгеләп куйганда;

1.6.2. сроклы хезмәт контракты төзегәндә;

1.6.3. граждан хезмәткәрен "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясындагы 2 өлешендә, 31 статьясындагы 1, 2 һәм 3 өлешләрендә каралган очракларда граждан хезмәтенең башка вазыйфасына билгеләп куйганда;

1.6.4. граждан хезмәтенең кадрлар резервына кертелгән граждан хезмәткәрен (гражданны) граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп куйганда.

1.7. Граждан хезмәтенең вазыйфаи бурычларына дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалану кертелгән аерым вазыйфаларына билгеләгәндә, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы боерыгы белән расланган вазыйфалар исемлеге буенча конкурс үткәрелмәскә мөмкин.

Граждан хезмәтенең кече вазыйфалары төркеменә карарган граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә яллаучы вәкиле карары белән конкурс үткәрелмәскә мөмкин.

1.8. Конкурс түбәндәге максатларда үткәрелә:

1.8.1. Россия Федерациясе гражданнарының, мөмкинлекләреннән һәм һөнәри әзерлек дәрәҗәләреннән чыгып, дәүләт граждан хезмәтен биләүгә тигез хокуклылыгын һәм шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләренең эш урынында конкурс нигезендә үсү хокукын тәэмин итү;

1.8.2. федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә туры килә торган һәм конкурста катнашырга рөхсәт ителгән кандидатлар арасыннан граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә иң лаеклы кандидатларны сайлап алу;

1.8.3. Министрлыкның кадрлар резервын булдыру.

1.9. Конкурс үткәргәндә хәл ителә торган мәсьәләләр:

1.9.1. кандидатлар конкурс биремнәрен һәм процедураларын башкарганда аларның барысы өчен дә тигез шартлар тәэмин итү;

1.9.2. конкурс комиссиясе әгъзалары бәяләре критерийлары буенча кандидатларны бәяләү (Боерыкка 5 нче кушымта);

1.9.3. конкурста катнашучылар арасыннан конкурс процедуралары барышында алынган объектив һәм нигезләнгән күрсәткечләрне чагыштыру

юлы белән граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфалары таләпләренә туры килә торган затларны билгеләү.

## 2. Конкурс комиссиясен булдыру һәм аның эш тәртибе

2.1. Министрлыкта конкурс үткәрү өчен Министр боерыгы белән конкурс комиссиясе төзелә.

2.1.1. Конкурс комиссиясе рәистән, рәис урынбасарыннан, секретарьдан һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2.2. Билгеләнмәгән вәкаләтләр чорына Министрлыкта граждан хезмәтенең "җитәкчеләр" категориясе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү өчен конкурс комиссиясен Министр җитәкли.

2.3. Комиссия рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә, утырыш үткәрү датасын билгели һәм аның көн тәртибен раслый, комиссия утырышларында рәислек итә һәм тиешле документларны имзалый. Комиссия рәисе булмаганда аның хокукларын һәм бурычларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясе рәисе конкурс процедураларын әзерләү һәм үткәрү буенча эшче төркем составын раслый.

Конкурс комиссиясе секретаре комиссиянең эшен тәэмин итә (конкурс документациясен теркәү, гаризалар кабул итү, эшләрне формалаштыру, комиссия беркетмәләрен алып бару һ.б).

2.4. Конкурс комиссиясе составына Министр урынбасарлары, кадрлар бүлеге, юридик бүлек башлыгы, Министрлыкның граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздырыла торган структур бүлекчәсе җитәкчесе яисә җитәкче урынбасары, Министрлыкның югары квалификацияле хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт хезмәткәрләре эшләре буенча департаменты вәкиле, шулай ук бәйсез экспертлар буларак Министр үтенече буенча Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт хезмәткәрләре эшләре буенча департаменты тарафыннан (әлеге экспертларның персональ белешмәләре күрсәтелми) чакырылган фәнни һәм мәгариф учреждениеләре, башка оешмалар вәкилләре – дәүләт хезмәте белгечләре кертелә.

Күрсәтелгән затлардан тыш, конкурс комиссиясе составына Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре дә кертелә. Әлеге вәкилләрнең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санының кимендә дүрттән берен тәшкил итәргә тиеш.

2.5. Дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалану вазыйфаи бурычларына кертелгән граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә

конкурс үткәрү өчен конкурс комиссиясе Россия Федерациясенең дәүләт сере турындагы законнар нигезләмәләрен истә тотып төзелә.

2.6. Конкурс комиссиясе составы конкурс карарлары кабул итүгә йогынты ясарлык мәнфәгатьләр конфликты килеп чыгу куркынычы калмаслык итеп төзелергә тиеш.

2.7. Конкурс комиссиясе утырышы граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына кимендә ике кандидат булганда үткәрелә һәм әгъзаларының кимендә өчтән икесе катнашса тулы хокуклы дип санала. Конкурс утырышын Министрлыкта дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын били торган әгъзалар катнашында гына үткәрү рөхсәт ителми.

2.8. Конкурс комиссиясе түбәндәге карарларны кабул итә:

2.8.1. конкурс үткәрү шартларын регламентлый торган документларны, аны үткәрү өчен кирәкле гамәли һәм башка материалларны раслау турында;

2.8.2. конкурс үткәрү план-графигын раслау турында;

2.8.3. конкурсның икенче этабына кертелгән кандидатлар исемлеген раслау турында;

2.8.4. конкурска йомгак ясау турында;

2.8.5. конкурс процедуралары буенча төзелгән рейтингта беренче урынны алган кандидатларны конкурста җиңүчеләр дип тану турында;

2.8.6. Татарстан Республикасы граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә Министрлыкның кадрлар резервына тәкъдим ителгән кандидатларның исемлеген төзү турында.

2.9. Конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча конкурс карары утырышта катнашкан конкурс комиссиясе әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда конкурс комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч булып санала. Конкурс комиссиясенең кабул ителгән карар белән килешмәгән теләсә кайсы әгъзасы үз фикерен белдерергә мөмкин, ул комиссия утырышы беркетмәсендә теркәлә һәм конкурс комиссиясенең әлеге әгъзасы имзасы белән раслана.

2.10. Конкурста катнашучыларга карата конкурс комиссиясе түбәндәге карарлар кабул итә:

2.10.1. граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә лаек, граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына билгеләү өчен тәкъдим ителә;

2.10.2. граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләү өчен куелган таләпләргә туры килә, тиешле кадрлар резервына кертү тәкъдим ителә;

2.10.3. граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләү өчен куелган таләпләргә туры килми.

2.11. Конкурс комиссиясе карары кандидат үзе булмаганда кабул ителә һәм граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына билгеләп кую яисә кадрлар резервына кертү өчен, яки кире кагу өчен нигез булып тора.

2.12. Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафынанн кабул ителә торган карарлар (тавыш бирү нәтиҗәләре) конкурс комиссиясе беркетмәсе белән рәсмиләштерелә (Нигезләмәгә 2 не кушымта), ул рәис, рәис урынбасары, секретарь һәм утырышта катнашкан комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

2.13. Конкурс процедурасын әзерләү һәм үткәрү документлары, конкурс комиссиясе утырышлары беркетмәләре, конкурс биремнәре сораулары һәм темалары конкурс тәмамланганчы хезмәт өчен файдалана торган документлар булып тора.

2.14. Конкурсны оештыру, аны үткәрү, конкурс комиссиясенең эше Министрлыкның кадрлар бүлеге тарафыннан башкарыла.

## 3. Конкурста катнашучылар

3.1. Конкурста катнашуга граждан хезмәтенең Министрлыкта вакант вазыйфасын биләү өчен куелган таләпләргә туры килә торган һәм билгеләнгән срокта барлык кирәкле документларны тапшырган гражданнар (алга таба – кандидатлар) кертелә.

Үзе граждан хезмәте вазыйфасы биләгән дәүләт органында конкурста катнашырга теләк белдергән граждан хезмәткәре министр исеменә (яллаучы вәкиле) гариза язарга тиеш.

Башка дәүләт органында конкурста катнашырга теләк белдергән граждан хезмәткәре бу дәүләт органына яллаучы вәкиле исеменә гариза һәм үз кулы белән тутырылган, имзаланган һәм үзе граждан хезмәте вазыйфасын били торган дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган, фоторәсем ябыштырылган анкета тапшыра. Анкета форматы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана.

Граждан хезмәтенең Министрлыкта вакант вазыйфаларын биләүгә кандидатларга таләпләр (Боерыкка 3 нче кушымта) һәм граждан хезмәтенең Министрлыкта вакант вазыйфаларын биләүгә кандидатлар тапшырган документлар һәм материаллар исемлеге (Боерыкка 4 нче кушымта) дәүләт граждан хезмәтен оештыру һәм үтү мәсьәләләрен регламентлый торган норматив хокукый актлар нигезендә билгеләнә.

3.2. Боерыкка 4 нче кушымтада саналган документлар, алар кабул ителү турында игълан ителгән көннән алып, 21 эчендә тапшырылырга тиеш.

3.3. Документларны үз вакытында тапшырмау, тулысынча тапшырмау яисә билгеләнгән кагыйдәләрне бозып тапшыру документларны гражданнан кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

Җитди сәбәпләр аркасында документларны үз вакытында тапшырмаганда, тулысынча тапшырмаганда яисә билгеләнгән кагыйдәләрне

бозып тапшырганда яллаучы вәкиле аларны кабул итү срокларын үзгәртергә мөмкин.

## 4. **Конкурсны үткәрү**

4.1. Конкурс үткәргәндә кандидатларны һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләүнең федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына каршы килми торган ысулларына нигезләнгән конкурс биремнәре һәм процедуралары кулланыла.

4.2. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү чикләре Министрлыкның граждан хезмәте вазыйфаларына куелган квалификация таләпләре нигезендә эшләнде.

Конкурста катнашучыларны бәяләү чикләренең кыскача һәм якынча тасвирламасы Боерыкка 5 нче кушымтада бирелде.

4.3. Кандидатларны чагыштырып карау һәм сайлап алу аларның конкурс биремнәрен үтәү һәм конкурс процедураларын үтү йомгаклары буенча башкарыла.

Нәтиҗәләр баллар буенча (рейтинг) кандидатлар исемлеге рәвешендә тәкъдим ителә.

4.4. Конкурс ике этапта үткәрелә.

4.4.1. Беренче этапта Министрлыкның Интернет челтәрендәге рәсми сайтына граждан хезмәтенең Министрлыкта вакант вазыйфасына (кадрлар резервына) конкурста катнашу өчен документлар кабул ителә башлау турында игълан (Нигезләмәгә 3 нче кушымта), шулай ук конкурс турында түбәндәге мәгълүмат: граждан хезмәтенең вакант вазыйфасы исеме, бу вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучыга таләпләр, граждан хезмәтен үтү шартлары, Боерыкка 4 нче кушымта нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты, әлеге документлар кабул ителә торган вакыт, конкурсны үткәрүнең якынча датасы, аны үткәрү урыны һәм тәртибе, башка мәгълүматлар урнаштырыла.

Конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында белдерү һәм дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру турында мәгълүмат (Нигезләмәгә 4 нче кушымта) вакытлы басма матбугатта да басылып чыгарга мөмкин.

4.4.2. Беренче этапта конкурс комиссиясе түбәндәгеләрне башкара:

4.4.2.1. кандидатларны һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләүнең федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына каршы килми торган ысулларына нигезләнгән аерым конкурс процедураларын билгели, моңа шәхси әңгәмә, анкета тутырту, төркемләп дискуссияләр үткәрү, гарждан хезмәтенең кандидатлар дәгъва кыла торган

вакант вазыйфасының вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле сораулар буенча реферат язу яисә тестлар эшләү керә;

4.4.2.2. конкурсны үткәрү методикасын, датасын, урынын, вакытын һәм аны үткәрү тәртибен билгели;

4.4.2.3. граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга конкурс турында мәгълүматлар бирә, консультацияләр үткәрә;

4.4.2.4. кандидатлар соравы буенча конкурс документларын бирә;

4.4.2.5. кандидатларның билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвенә алдан бәяләү уздыра.

4.4.3. Конкурс комиссиясе секретаре конкурс комиссиясе утырышы үткәрүгә кимендә биш эш көне кала конкурс комиссиясенең барлык әгъзаларына конкурста катнашучылар тапшырган документларның күчермәләрен тапшыра.

4.4.4. Граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә кандидатлар тапшырган документларны тикшергәннән соң, дәүләт серен һәм законнар белән саклана торган башка серне тәшкил итә торган белешмәләргә рөхсәт бирүне рәсмиләштерү зарурлыгы булганда, конкурс комиссиясе гражданнарга (граждан хезмәткәрләренә) конкурста катнашырга рөхсәт итү яисә дәлилләнгән баш тарту турында карар кабул итү өчен Министрга тәкъдим кертә.

Кандидатларның тикшерелгән документлары һәм конкурс комиссиясе тәкъдиме конкурсның икенче этабын үткәрү турында карар кабул итү өчен Министрга тапшырыла.

4.4.5. Тикшерү барышында гражданның граждан хезмәте үтүенә федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә каршы килә торган хәлләр ачыкланганда, конкурста катнашуга каршы килүнең сәбәпләре турында кадрлар бүлеге тарафыннан кандадатка язмача хәбәр ителә (Нигезләмәгә 5 нче кушымта)

4.4.6. Конкурска кертелмәгән вакант вазыйфага дәгъва кылучы бу карарга Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять белдерергә мөмкин.

4.4.7. Конкурсның беренче этабын тәмамлау өчен билгеләнгән таләпләргә туры килә торган ике һәм аннан күбрәк кандидатның булуы шарт, бу – кандидатларны алга таба сайлап алу мөкинлеген тәэмин итә.

Билгеләнгән таләпләргә туры килә торган һәм конкурста катнашуны дәвам итәргә тәкъдим ителгән кандидатларның исемлеген төзү беренче этапның нәтиҗәсе булып тора, ул конкурс комиссиясе карары белән раслана.

Конкурсның икенче этабы башланырга кимендә 15 көн кала кадрлар бүлеге конкурска кертелгән кандидатларга аны үткәрүнең датасы, урыны һәм вакыты турында хәбәр итә (Нигезләмәгә 6 нчы кушымта).

4.4.8. Конкурсның икенче этабы өч төрле рәвештә үткәрелә.

4.4.8.1. Граждан хезмәтенең өлкән вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәргәндә икенче этап кандидатлар тапшырган документларны анализлаудан һәм структур бүлекчәләрнең җитәкчеләре белән шәхси әңгәмәдән гыйбарәт.

4.4.8.2. Граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфаларына конкурс үткәргәндә икенче этапта түбәндәгеләр уздырыла:

а) кандидатлар тапшырган документларга анализ;

б) структур бүлекчәләрнең җитәкчеләре белән шәхси әңгәмә.

Әлеге төркем вазыйфалары өчен конкурсның икенче этабында кандидатларны бәяләгәндә кандидатларны һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләүнең федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына каршы килми торган ысулларына нигезләнгән аерым конкурс биремнәре һәм процедуралары (компьютер ярдәмендә яисә бланкта тестлар аша) кулланылырга мөмкин.

4.4.8.3. Граждан хезмәтенең баш вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәргәндә икенче этап кандидатлар тапшырган документларны анализлаудан, аналитик эшләрне (рефератлар) бәяләүдән, шулай ук Министрлык җитәкчеләре белән шәхси әңгәмәдән гыйбарәт.

Әлеге төркем вазыйфалары өчен кандидатларның формалаштырылган ысуллар (тестлар), шулай ук төркемләп дискуссия һәм махсус биремнәр анализына нигезләнеп һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү үткәрелә. Биремнәрнең характеры һәм кандидатларга тәкъдим ителә торган темалар бәйсез экспертлар тәкъдимнәре нигезендә төзелә һәм конкурс комиссиясе тарафыннан раслана.

4.4.9. Тест сынаулары язмача үткәрелә. Конкурс комиссиясе кандидатлар өчен тест сораулары әзерли, шулай ук дөрес булмаган сорауларның чик күләмен (яисә процентын) раслый. Дөрес булмаган җавапларның рөхсәт ителә торган күләме 25 проценттан артмаска тиеш.

Сораулар белән танышу рөхсәт ителергә тиеш. Тест сораулар нигезендә төзелә һәм кандидатларның түбәндәгеләрне белүен ачыклый:

а) Россия Федерациясе Конституциясен һәм Татарстан Республикасы Конституциясен;

б) федераль законнарны һәм Татарстан Республикасы законнарын;

в) дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе законнарын һәм Татарстан Республикасы законнарын;

г) Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы турында нигезләмәне;

д) дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасының вазыйфаи регламентын;

е) структур бүлекчә эшчәнлеге буенча норматив хокукый актларны һ.б.

Тестта иң күбе 50 сорау булырга тиеш.

Дөрес җаваплар тигез булган очракта катнашучыларга, җавап бирү өчен вакыт билгеләп, өстәмә тестлар бирелә.

4.4.10. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләгәндә конкурс комиссиясе граждан хезмәте вазыйфасына тиешле квалификация таләпләреннән һәм бу вазыйфа буенча вазыйфаи регламентның башка нигезләмәләреннән, шулай ук әлеге Нигезләмә һәм дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән нигезләмәләрдән чыгып эш итә.

4.4.11. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын конкурс комиссиясе әгъзалары кадрлар бүлеге тарафыннан һәрбер конкурска әзерләнә торган бәяләү кәгазендә теркәп бара.

4.4.12. Конкурс башланыр алдыннан конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүче конкурс комиссиясе әгъзаларына утырышны үткәрү тәртибе, бәяләр кую, конкурс әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары турында инструкция уздыра.

4.4.13. Конкурсн комиссиясенең һәрбер әгъзасы конкурс комиссиясе секретареннан конкурста катнашучыларны бәяләү кәгазьләре ала һәм тиешле балларны куя. Һәрбер бәяләү кәгазендә балларның гомуми санын куйганнан соң, конкурс әгъзасы бәяләү кәгазен имзалый һәм аларны конкурс секретарена тапшыра.

4.4.14. Бәяләү кәгазьләре нигезендә конкурс комиссиясе секретаре конкурста катнашучы һәр зат буенча балларның гомуми санын билгели.

Бәяләү кәгазендә төзәтүләр рөхсәт ителми.

Кандидатларны бәяләүнең иң соңгы нәтиҗәләре Вакант вазыйфаны биләү өчен кандидатның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү анкетасына (Нигезләмәгә 7 нче кушымта) теркәлә.

4.5. Дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә кандидатларның конкурс комиссиясе тарафыннан әзерләнгән рейтинглары икенче этап һәм бер үк вакытта конкурс нәтиҗәләре булып тора.

Конкурсны йомгаклау һәм дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә кандидат турында карар кабул итү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

4.5.1. кандидатларның барлык конкурс процедураларын үтү нәтиҗәсе буенча алынган бәяләү критерийләре буенча баллар суммасы;

5.5.2. кандидатлар дәгъва кыла торган вазыйфа караган структур бүлекчә җитәкчесенең (Министрлык җитәкчеләренең) кандидатлар белән шәхси әңгәмә (әңгәмәләр) нәтиҗәсендә туган фикере.

Конкурс комиссиясе конкурста җиңүче турында карарны һәм Министрлыкның кадрлар резервына кертергә тәкъдим ителгән кандидатлар исемлеген раслый.

4.6. Дәүләт граждан хезмәтенең конкурс үткәрелгән вакант вазыйфасы буенча барлык таләпләргә туры килә торган кандидатлар конкурс нәтиҗәсендә ачыкланмаса, конкурс комиссиясе өстәмә конкурс сынаулары үткәрү турында карар кабул итәргә яисә яңа конкурс үткәрү турында тәкъдим кертергә хокуклы.

4.7. Министр яңа конкурс үткәрү турында яисә дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә иң лаек һәм иң күп баллар җыйган кандидатны граждан хезмәте вазыйфасына максималь сынау срогы белән билгеләп кую турында карар кабул итә.

4.8. Конкурсның ике яисә берничә катнашучысы тигез күләмдә баллар җыйган очракта, конкурс комиссиясе рәисе фикере хәлиткеч булып санала.

4.9. Конкурс нәтиҗәләре конкурс комиссиясе карары белән рәсмиләштерелә, ул конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүче, конкурс комиссиясе секретаре һәм утырышта катнашкан әгъзалар тарафынанан имзалана. Конкурс комиссиясе карарында граждан хезмәтенә беренче тапкыр алынган гражданга яисә Министрлыкта башка төркемгә яки категориягә күчерелгән граждан хезмәткәренә сынау срогы билгеләүнең дәвамлылыгы турында тәкъдимнәр булырга мөмкин.

4.10. Конкурс нәтиҗәләре буенча дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына конкурста җиңүчене билгеләп кую турында Министр боерыгы чыгарыла, аның белән хезмәт контракты төзелә.

Граждан хезмәткәрен (гражданны) – конкурста җиңүчене кадрлар резервына кертү Министр боерыгы белән рәсмиләштерелә һәм граждан хезмәткәренең шәхси эше папкасына һәм граждан хезмәкәренең хезмәтен раслый торган башка документларга тиешле язу теркәлә.

Министрга конкурста җиңүчене вазыйфага билгеләп кую өчен тәкъдим иткәндә, вазыйфалар номенклатурасы нигезендә, конкурс комиссиясе карары һәм комиссиянең мондый карар кабул итүе өчен нигез булып торган материаллар тапшырыла.

4.11. Конкурста катнашкан кандидатларга кадрлар бүлеге конкурс нәтиҗәләре турында конкурс тәмаланган көннән алып җиде көн эчендә язмача хәбәр итә (Нигезләмәгә 8 нче кушымта) һәм тиешле мәгълүмат әзерли (Нигезләмәгә 9 нчы кушымта).

Конкурс нәтиҗәләр турында мәгълүмат Министрлык сайтына урнаштырыла.

4.12. Кандидат конкурс комиссиясе карарына Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять белдерергә мөмкин.

4.13. Конкурста катнашырга кертелмәгән дәгъва кылучыларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары конкурс тәмамланганнан соң өч ел эчендә аларның язмача гаризалары нигезендә кире кайтарылырга мөмкин. Бу вакыт узганнан соң документлар Министрлык архивында саклана, аннан соң юкка чыгарыла.

4.14. Конкурста катнашуга бәйле матди чыгымнар (конкурс үткәрү урынына бару һәм кире кайту, торак, яшәү, элемтә чараларыннан файдалану чыгымнары һәм башкалар) кандидатларның үз акчалары исәбеннән башкарыла.